СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.04.2026 г. Агрыз № 10-13

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнар таләпләренә туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайты бүлекләрен коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруга һәм тутыруга таләпләрне раслау турында» 2014 елның 30 октябрендәге 36-3 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында» 2022 елның 26 октябрендәге 20-3 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында» 2023 елның 19 гыйнварындагы 25-5 номерлы.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов